РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«17» июнь 2021 г. г. Альметьевск № 59

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы
хокуклар турында белешмәләр бирү хакында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указын үтәү йөзеннән

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы, муниципаль хезмәт вазыйфаларын алып баручы гражданнар, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар үзләренең, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр, мелкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 2 октябрендәге 402 номерлы карары белән расланган «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәр, мелкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә хакында» карары нигезендә, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаларын биләүче гражданнар, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының «Россия Федерациясе Президентының керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган белешмәләр белән бергә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы 1 нче кушымта нигезендә, үзләре ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларына карый торган цифрлы финанс активлары һәм башка цифрлы хокуклар, утилитар цифрлы цифрлы хокуклар һәм цифрлы валюта (алар булган очракта) турында хәбәрләр тапшыра.

Заказ № 2625

2. Район Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советеның законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»